ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.05.2023 г. Заинск № 312

**Зәй муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм тулыландыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 25 июлендәге 1119 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Расларга:

1.1. Зәй муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турында нигезләмәне (1 нче кушымта).

1.2. Зәй муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның номенклатурасын һәм күләмен (2 нче кушымта).

2. Зәй муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен резервта матди ресурслар

булдыру буенча җитәкчелек итүне һәм аны коодинацияләүне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына һәм инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

3. Зәй муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

3.1. Ведомство карамагындагы объектларда җирле һәм объект дәрәҗәсендәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдырырга.

3.2. Объект территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бәяләүдән чыгып, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервының номенклатурасын һәм күләмен билгеләргә.

4. Зәй муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның муниципаль резервын булдыру, саклау, куллану һәм тулыландыру буенча эшләрне финанслау Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

5. «Зәй муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2016 елның 25 июлендәге 1587 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Карар рәсми басылып чыкканнан соң законлы көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.М. Хаҗиповка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

А.Х. Әхмәтҗанов
8(85558) 7-40-09

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 03 05
312 номерлы карарына 1 кушымта

Зәй муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турында
НИГЕЗЛӘМӘ

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм тулыландыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 25 июлендәге 1119 номерлы карары, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып эшләнгән.

2. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта кирәкле чараларны ашыгыч җәлеп итү максатыннан алдан ук булдырыла һәм азык-төлек, азык-төлек чималы, медицина милке, медикаментлар, төзелеш материаллары, ягулык һәм башка матди ресурсларны үз эченә ала.

3. Зәй муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары системасы үз эченә ала:

— җирле резерв - Зәй муниципаль районының муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен резервы;

— объект резервы - объект территориясендә гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның резервлары.

## II. Матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, куллану һәм тулыландыру тәртибе

4. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларының номенклатурасын һәм күләмнәрен билгеләү, шулай ук күрсәтелгән резервларны булдыру, саклау, куллану һәм тулыландыруны контрольдә тоту аларны булдырган орган яки оешма тарафыннан башкарыла.

5. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен җирле матди ресурслар резервын продукция белән тәэмин итүчеләрне сайлау “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның резервларын формалаштыру гадәттән тыш хәл янаган яисә килеп чыккан очракта оешмалар белән тиешле товарларны китерүгә килешүләр төзү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

7. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен җирле резерв булдыру өчен матди ресурслар заказчылары булып тора:

Зәй муниципаль районы башкарма комитеты - азык-төлек, әйберләр, беренчел кирәк-яраклар, нефть продуктлары, төзелеш материаллары, җиһазлар һәм башка матди ресурслар буенча;

"Зәй үзәк район хастаханәсе" ДАССУ — медицина мөлкәте, медицина техникасы, дарулар буенча;

8. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары аларны саклау өчен билгеләнгән аннан аларны гадәттән тыш хәлләр зоналарына оператив китерү мөмкин булган объектларда урнаштырыла.

9. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары түбәндәгеләр өчен файдаланыла:

— торак-коммуналь хуҗалык объектларында, социаль даирәдә һәм башка объектларда кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янауны бетерү буенча авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен;

— зыян күргән гражданнарның вакытлыча яшәү һәм туклану пунктларын җәелдерү һәм тоту өчен;

— халыкка бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү өчен;

— зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле башка беренчел чараларны үткәрү өчен.

10. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары кулланыла, шул исәптән:

а) җирле матди чаралар резервы, шул исәптән:

азык-төлек, әйберләр, беренче кирәкле әйберләр, нефть продуктлары, материаллар һәм җиһазлар, медицина милке, медицина техникасы, дарулар, шулай ук төзелеш материаллары һәм җиһазлар Зәй муниципаль районының

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе күрсәтмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла;

б) матди чараларның объект резервлары — оешма администрацияләре билгеләгән тәртиптә.

11. Локаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен объект резервлары кулланыла. Үз средстволары җитәрлек булмаганда предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан, таләп ителә торган ресурсларның күләмнәрен һәм номенклатурасын нигезләп, матди ресурсларның резервлары исәбеннән ярдәм күрсәтү турында югарырак органнарга гариза тапшырыла.

Муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, аларны бетерү өчен, Зәй муниципаль районы резервларының матди ресурслары файдаланыла. Алар җитәрлек булмаганда, Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органы, республика резервыннан матди ресурслар бүлеп бирүне сорап, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Муниципаль һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү һәм зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе, аларны төзегән органнар һәм оешмалар белән килештереп, матди ресурсларның булган резервларыннан файдаланырга мөмкин.

12. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары гадәттән тыш хәлләрне бетерү белән бәйле булмаган башка максатларга аларны булдырган органнар кабул иткән карарлар нигезендә генә кулланыла ала.

13. Гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә сарыф ителгән матди ресурсларның җирле резервын тулыландыру алар мәнфәгатьләрендә кулланылган оешмаларның акчалары яки тиешле органнар карары буенча башка акчалар хисабына башкарыла.

## III. Матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, куллану һәм тулыландыру чыгымнарын финанслау

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, куллану һәм тулыландыру чыгымнарын финанслау тиешле резервлар булдырган органнар, оешмалар акчалары хисабына башкарыла.

14. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу мөмкинлеге зонасында булган предприятиеләр һәм оешмаларның иминият фондлары акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына финансланырга мөмкин.

15. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары продукциясен сатып алуга кирәкле финанс средстволары күләме матди ресурсларга базар бәяләренең үзгәрүе мөмкинлеген, шулай ук резервларны

формалаштыру, урнаштыру, саклау һәм тулыландыру белән бәйле чыгымнарны исәпкә алып билгеләнә.

## IV. Җирле матди ресурслар резервын булдыруны, саклауны, куллануны һәм тулыландыруны исәпкә алу һәм контроль тәртибе

17. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен җирле матди ресурслар резервы булдыруны, саклауны, куллануны һәм тулыландыруны исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны оештыралар:

Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты — азык-төлек, әйберләтә мөлкәт, беренчел кирәк-яраклар, нефть продуктлары, төзелеш материаллары, җиһазлар һәм башка матди ресурслар буенча;

"Зәй үзәк район хастаханәсе" ДАССУ — медицина мөлкәте, медицина техникасы, дарулар буенча;

18. Җирле резервны һәм матди ресурсларның объект резервларын туплауны, саклауны, яңартуны оештыру буенча контрольне Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 03 05
312 номерлы карарына 2 кушымта

Зәй муниципаль районының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар номенклатурасы һәм күләме

| № п/п | Матди ресурсларның аталышы | Үлч. бер. | Планлаштырыла торган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| **1.** | **Азык-төлек, шул исәптән (3 тәүлеккә зыян күргән 50 кеше исәбеннән + 50 коткару хезмәтләре хезмәткәрләре)** | | |
| 1. | 1 нче сортлы арыш һәм бодай оны катнашмасыннан икмәк | кг. | 90 |
| 2. | 1 нче сортлы бодай онынннан икмәк | кг. | 105 |
| 3. | 1 нче сортлы бодай оны | кг. | 15 |
| 4. | Сыер мае | кг. | 13,5 |
| 5. | Үсемлек мае | кг. | 9 |
| 6. | Ит яки ит консервалары | кг. | 25 |
| 7. | Балык консервалары | кг. | 11 |
| 8. | Каты сыр | кг. | 3 |
| 9. | Төрле ярмалар һәм токмачлар | кг. | 45 |
| 10. | Шикәр | кг. | 13,5 |
| 11. | Чәй | кг. | 0,3 |
| 12. | Бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимешләр | кг. | 270 |
| 13. | Җимеш һәм җиләк соклары | л. | 3 |
| 14. | Тоз | кг. | 6 |
| 15. | Шырпы | кап | 50 |
| 16. | Коры сөт, сөт консервалары | кг./данә | 30 |
| 17. | Йомырка | шт. | 300 |
| 18. | Киптерелгән җиләк-җимеш (йөзем, күрәгә, караҗимеш) | кг. | 3 |
| 19. | Балалар ризыгы | кг. | 5 |
| 20. | Коры паек | к-т | 150 |
| **2.** | Әйберләтә мөлкәт, беренче чиратта кирәк-ярак предметлар, шул исәптән | | |
| 1. | Унификацияләнгән көнкүреш палаткасы | к-т | 1 |
| 2. | Каркаслы җәйге солдат палаткасы | к-т | 1 |
| 3. | Медицина палаткасы (ПМК) | к-т | 1 |
| 4. | Җылыту җиһазлары (рефлектор, радиатор, каты һәм сыек ягулык белән ягыла торган мичләр) | данә | 3 |
| 5. | Савыт-саба (кружка, калак, тәлинкә) | к-т | 50 |
| 6. | Караватъ (шул исәптән җәелә-җыела торган) | данә | 50 |

| № п/п | Матди ресурсларның аталышы | Үлч. бер. | Планлаштырыла торган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 7. | Матрас | данә | 50 |
| 8. | Мендәр | данә | 50 |
| 9. | Йон яки мамык юрган | данә | 50 |
| 10. | Җәймә (простыня) | данә | 100 |
| 11. | Мендәр тышы | данә | 50 |
| 12. | Сөлге | данә | 50 |
| 13. | Аяк киеме: күн, резина, басылган һ. б. (шул исәптән 30% балаларныкы) | к-т | 50 |
| 14. | Җылы кышкы кием (шул исәптән 30% балаларныкы) | к-т | 50 |
| 15. | Баш киеме: кышкы, җәйге | кг. | 57 |
| 16. | Кер сабыны | кг. | 300 |
| 17. | Яктырту өчен керосин | л. | 40 |
| 18. | Стеарин шәм | данә | 100 |
| 19. | «Ярканат» фонаре | к-т | 20 |
| 20. | Коткаручылар өчен махсус кием (кышкы, җәйге) | к-т | 50 |
| 21. | Бияләй, эш перчаткалары, җылытылган | к-т | 50 |
| **3.** | **Төзелеш материаллары һәм җиһазлар** | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан билгеләнә | |
| **4.** | **Нефть продуктлары, шул исәптән:** | | |
| 1. | АИ – 92 номерлы автомобиль бензины | тн. | 3 |
| 2. | Дизель ягулыгы | тн. | 2 |
| 3. | Карбюраторлы двигательләр өчен автомобиль мае | кг. | 200 |
| 4. | Дизель двигательләр өчен автомобиль мае | кг. | 200 |
| **5.** | Медицина мөлкәте, медицина техникасы, дару препаратлары | "Зәй РҮХ" ДАССУ тарафыннан билгеләнә | |
| **6.** | **Башка матди ресурслар** | | |
| 1. | «Ребир» моторлы пычкысы | данә | 1 |
| 2. | Трослы кул чыгыры (лебедка) | данә | 1 |
| 3. | Газ белән эретеп ябыштыру җиһазлары комплекты | данә | 1 |
| 4. | Гидравлик домкрат | данә | 1 |
| 5. | Слесарь кораллары җыелмасы | данә | 1 |
| 6. | Дисклы электр пычкысы | данә | 1 |
| 7. | Тагылма кыр кухнясы | данә | 1 |
| 8. | Пневматик һәм электромеханик приводлы кече механизация чаралары (дрель, перфоратор, шлиф. Машинкалар һ.б.) | к-т | 1 |
| 9. | Кул (шанцевый) инструментлары (балта, лом, багор, пычкы, көрәк, шлямбур (тишкеч), кадак суыргыч, каргаборын) | к-т | 1 |
| 10. | ТВН-12 термосы (метал. 3л.) | данә | 2 |
| 11. | Беркеткечләр, кадаклар | кг. | 700 |
| 12. | Изолятор (аергыч) | данә | 5 |
| 13. | Янмый торган электр үткәргече | м. | 335 |
| 14. | Үткәргеч (А-35) | кг. | 85 |

| №<br>п/п | Матди ресурсларның аталышы | Үлч.<br>бер. | Планлаштырыла торган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 15. | Түбән вольтлы көч кабеле (1 КВт) | м. | 85 |
| 16. | Көч трансформаторы (100 А) | данә | 1 |
| 17. | Коры зарядлы аккумулятор 6 ст. 75 А | данә | 1 |
| 18. | ГП-7 граждан противогазы | данә | 50 |
| 19. | Л-I (ОЗК) саклагыч костюмы | к-т | 50 |
| 20. | ИП-4 изоляцияли торган противогаз | данә | 10 |
| 21. | РП-4 регенератив патроны | данә | 20 |
| 22. | Электромегафон | данә | 1 |
| 23. | Автомобиль радиостанциясе | к-т | 1 |
| 24. | Күчмә электр станциясе,8 КВт | к-т | 1 |